| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 май № 354

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 октябрь, 741 нче, 2016 ел, 22 февраль, 104 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлындагы унбишенче абзацны төшереп калдырырга;

Программаның I бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Программа дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган, Татарстан Республикасында коррупцияне кисәтү, коррупциячел хокук бозуларны мөмкин булганча киметү буенча эштә төгәл нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән, хокукый, белем бирү, тәрбияләү, оештыру һәм бүтән чараларны килешеп куллануны тәэмин иткән комплексы чаралар системасын тәшкил итә.»;

Программаның II бүлегендәге егерме җиденче абзацны төшереп калдырырга;

Программаның IV бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы Программаның аерым чаралары үтәлеше мәсьәләләре буенча Программаның үтәүчеләре белән квартал саен киңәшмәләр үткәрә.»;

Программага кушымтада:

1.2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.2.2. Дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте турында законнарда каралган хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт турында законнарда каралган чикләүләр һәм тыюларны үтәүләренә, шул исәптән Россия Федерациясе федераль салым хезмәтенең «Юридик затларның бердәм дәүләт реестры» һәм «Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестры» мәгълүматлар базаларыннан файдаланып, эшмәкәрлек эшчәнлегендә катнашу предметына тикшерүләр үткәрү (кимендә елга бер тапкыр) | ТР ДХБО һәм ҖҮО (килешү буенча) | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләре каршындагы коррупциягә каршы тору комиссияләре, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларындагы коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссияләре эшчәнлегенең, шул исәптән аларның эшчәнлегенә иҗтимагый советлар вәкилләрен һәм башка гражданнар җәмгыяте институтлары вәкилләрен җәлеп итү юлы белән, ачыклыгын тәэмин итү | ТР ДХО һәм ҖҮО (килешү буенча) | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |

түбәндәге эчтәлекле 1.3.1 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.3.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләре каршындагы коррупциягә каршы тору комиссияләре, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларындагы коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссияләре эшенең еллык планнарын | ТР ДХБО, ҖҮО (килешү буенча) | 2016 – 2020 еллар. | Бер елда тиешле комиссияләр үткәргән утырышлар саны | | | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | - | -»; |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| раслауны һәм киләчәктә аларны үтәүне тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | |

4.20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «4.20. Дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләр тарафыннан чикләүләр, тыюлар, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән вазыйфаларын үтәү буенча, шул исәптән бүләкләр бирү һәм алуга кагылышлы чикләүләрне үтәү буенча оештыру, аңлату һәм бүтән чаралар комплексын гамәлгә ашыру, әлеге эшкә Татарстан Республикасы башкарма органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары каршындагы иҗтимагый советларны, коррупциягә каршы торуда катнашучы иҗтимагый берләшмәләрне һәм башка гражданнар җәмгыяте институтларын җәлеп итеп | ТР ДХБО һәм ҖҮО (килешү буенча) | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | -»; |

5.2 пунктның 8 графасында «80» саннарын «85» саннарына алмаштырырга;

5.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.11. ММЧда урнаштырылган һәм гражданнар һәм юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләрдә булган вазыйфаи затлар эшчәнлегендә коррупция чагылышлары турында мәгълүмат мониторингын үткәрү буенча эшне оештыру, аның нәтиҗәләрен квартал саен гомумиләштерү һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләре каршындагы коррупциягә каршы тору комиссияләре, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларындагы коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссияләре утырышларында карап тикшерү | ТР ДХБО һәм ҖҮО (килешү буенча) | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |

9.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «9.1. Гражданнар дәүләт (муниципаль) хезмәт вазыйфасына кергәндә барлыкка килә торган коррупция куркынычларын бетерү максатында дәүләт граждан (муниципаль) хезмәте өлкәсендә законнар таләпләрен үтәүне тәэмин итү | ТР ДХБО, ҖҮО (килешү буенча) | 2015 – 2020 еллар | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |

9.9 пунктны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 9.14 – 9.17 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «9.14. Коррупциячел күренешләрне киметү һәм су һәм урман законнарын бозуны кисәтү өчен чаралар күрү; халыкны урманнардан һәм су саклау зоналарыннан законсыз файдалану белән бәйле хокук бозуларны табуга җәлеп итү максатында «Халык и нвента-ризациясе» акцияләрен үткәрү | ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы, ТР Урман хуҗалыгы министрлыгы | 2016 – 2017 еллар | Үткәрелгән акцияләр саны | | | 2 | 2 | | | | - | - | - | - | - | - |
| 9.15. Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюлар, чикләүләр һәм таләпләрне сакламауның һәр очрагында законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру | ТР ДХБО, ҖҮО (килешү буенча) | 2016 – 2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |
| 9.16. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары алдына куелган бурычларны үтәү өчен төзелгән оешмаларда коррупцияне кисәтү буенча оештыру, аңлату һәм бүтән чаралар комплексын гамәлгә ашыру | ТР ДХББО һәм ТР ДХБО ведомствосындагы учреждениеләр (килешү буенча) | 2016 – 2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |
| 9.17. Дәүләт граждан һәм муни-ципаль хезмәтендә мәнфәгатьләр каршылыкларын булдырмау һәм җайга салу турында законнар таләпләрен үтәүне тәэмин итү | ТР ДХБО, ҖҮО (килешү буенча) | 2016 – 2020 еллар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | -»; |

Файдаланылган кыскартулар исемлегендә:

ундүртенче, егерме җиденче, кырык беренче абзацларны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы;

ТР Урман хуҗалыгы министрлыгы – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков